СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2022 Баулы шәһәре №139

Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районының бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 150 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладларын күтәрү турында» 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районының бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 150 номерлы карарына (2018 елның 28 сентябрендәге 177 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 275 номерлы, 2022 елның 22 февралендәге 104 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәре Баулы муниципаль районында аерым бюджет даирәсе оешмасының (бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган) структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазифаи оклады күләменә карата бермә-бер арттырыла, ул 11 958 сум тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе И.И. Гозәеров